**Корылтай мөнбәреннән әйтер идем**

# «Конгресс сәясәт белән дә шөгыльләнергә тиеш»

**Декабрь башында Казанда узачак Бөтендөнья татар конгрессының корылтаена Самардан тугыз делегат, өч шәрәфле кунак һәм ике журналист барачак.**

**Конгресс мөнбәреннән сөйләргә сүз бирсәләр, яңа Башкарма комитетка нинди теләкләр белдерер идегез, дигән сорауга Самар шәһәренең татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе, делегат Рифкат Хуҗин түбәндәге җавапны бирде.**

- Беренчедән, әле эшләп килгән Башкарма комитетка мин рәхмәтләремне әйтер идем. Соңгы биш елда Конгресс зур көчләр куеп Сабан туебызны Тын океанга кадәр җиткезде. Ил буйлап гөрләтеп авыл Сабан туйлары уза. Федераль күләмдә ат чабышлары узды. "Түгәрәк уен"нар гөрли. Бәйрәмнәр күп булсын, чөнки бу халык белән очрашу урыны гына түгел, бу халык белән аралашу җире дә.



Заман үзгәрә, алгы сафка сәясәт чыга. Русия буйлап милләтләргә каршы яу башланды. Бу очракта да атакага татарлар ыргытылырга тиеш. Калган милләтләр татар арбасына гына утыручылар. Русиянең төп канунын үзгәртергә теләүчеләр, милли мәгарифне юкка чыгаручылар көчәйгәннәнкөчәя бара. Конгресста бик көчле юристлар төркеме эшләргә тиеш. Милләтләргә каршы, динебез Исламга каршы чыгучыларның фикерләрен туплап анализларга һәм һәр милли оешмага юнәлтергә кирәк. Үз чиратында, төбәкләрдәге милли оешмалар да үз позицияләрен белгертеп Конгресска мәгълүмат җибәрергә тиешләр. Әлбәттә, төбәкләр канәгатьсезлекләрен белдереп язган хатларын Русия президенты аппаратына, хөкүмәт даирәләренә, Татарстан җитәкчеләренә, төбәк депутатларына да җибәрергә тиешләр.

*Шамил БАҺАУТДИН.*

**Мәдәни тормыш**

# Күргәзмәдә Самар Җәмигъ мәсҗиден дә күрәсе килгән иде

Самарның Ак йорты каршындагы мәйдан Дан мәйданы исемен йөртә. Һәм өстәргә кирәк - шәһәрнең иң матур мәйданы. Менә шул киңлектә, иркенлектә бик зур гына фотокүргәзмә урын алган.

"Россия буйлап сәяхәт" дип исемләнгән күргәзмәгә йөз утызга якын фотосурәт эленгән. Һөнәрмәнд фотографлар Идел буе төбәкләренең иң-иң гүзәл урыннарын күрсәтергә тырышканнар һәм урыс тамашачысы күзләгеннән караганда максатларына ирешкәннәр дә, дип әйтергә була.

Дүрт ел элек, Россия тарихында беренче мәртәбә, Самар, Ульян өлкәләре һәм Татарстан туристик сәяхәтләрнең уртак маршрутларын булдыралар. Таркалган дәүләттә беренче мәртәбә төбәкара берләшү сәясәте туа. Тора-бара шул өчлеккә Тверь, Пенза, Сарытау, Пермь, Түбән Новгород өлкәләре, Марий Эл, Башкортстан һәм Чувашия кушылалар. Бу рәсми кәгазьләрдә шулай диелә. Ә менә реклам битләрендә нигәдер Татарстан исемлекнең соңгы урынында.

Идел буе туризм сәясәте унбер төбәкне колачлап, үзенә күрә бер монстрга әйләнгән. Бу берлекне оештыруда берничә департамент, милли республикаларда министрлыклар катнашкан. Күргәзмә мәдәни күзлектән төбәкнең җәүһәрләрен пропагандалауны максат итеп куйган. Һичшиксез, табигатьнең хозурлыгын, үзенчәлеген, кабатланмаганлыгын күрсәткән кадрлар бар. Мәсәлән, Самар өлкәсендәге ел әйләнәсенә туңмый торган унсигез метр тирәнлектәге кечкенә генә күл!

Ульян шәһәре янындагы Идел аркылы күперне кайда әле шулай күзаллый аласың! Ләкин дә шундый үзенчәлекле, күңелгә иркенлек, җанга сафлык өсти торган сурәтләр күпчелек очракта чиркәүләр, монастырьлар аша бирелгән. Йөздән артык фотосурәтне карап чыккач, тулаем бер образ туа. Әйтерсең лә син Россия чиркәүләренең фотомонтажын карап чыктың диярсең. Һәр төбәктә чиркәүләр, чиркәүләр һәм монастырьлар. Ә бит шул ук төбәкләрдә матурдан-матур мәчетләр бар ләбаса!

Самар Җәмигъ мәчетенең архитектура үзенчәлеген, зурлыгын исәпкә алсаң, һәм толерантлык турында сөйләп кенә түгел, күрсәтсәң дә, менә булыр иде хөрмәт һәм түземлелек. Самар бүлегендә төбәктә мөселманлыкның әсәре дә юк.

Шундый зур күргәзмәгә Татарстан үзенең йөзен күрсәтер өчен тырышкандыр, дип юнәлгән идем. Кайда ул! Күрәсең, барчасын да фотограф Агарков карамагына биргәннәр. Төп герой - Свияжск! Аның турында биш фото. Тәреләр, тәреләр. Болгар турында ләм-мим. Ә бит Болгарда һәркем сокланырлык Ак мәчет салдылар. Сөембикә манарасын янындагы бина белән төшергәннәр. Ялгышмасам, безнекеләр ул бинаны "Нурали" мәчете дип йөртәләр. Агарков аңа "Дворцовская церковь" кушкан. Казанның авыл хуҗалыгы йортын мактаган, ләкин дә аның матурлыгын күрер өчен Благовещенск соборы янына басып карарга кирәк, дип яза Агарков. Шәхсән мин үзем Казанда булганда бу бинаның шедеврлыгын чиркәү янына бармый да күрдем. Ничек инде ул бинаның матурлыгын бер ноктадан гына күзалларга була ди? Һәм ни өчен ул нокта чиркәүгә бәйләнергә тиеш икән соң?

Казанның Петропаул чиркәвен дә зурлаган фотограф. Дөрес эшләгән. Матур бина. Ләкин дә нигә бер Свияжскидан биш фото, шуның икесе алачыктан. Шундый җаваплы күргәзмәләргә дә экспонатны Татарстан мәдәният министрлыгы үзе сайламыйча, Агарковларга тапшыргач, республиканы читләрдә ничек пропагандаларга була ди соң?

Менә шуңа да Самар яшьләре Казанны карарга барганда арендага автобус алалар да, кая барасын үзләре хәл итәләр. Читтәге татарлар Казанның татарлыгын күрәселәре килә. Самар байлары гаиләләре белән Казан кунакханәләрендә торып, үзләре теләгән татар мохитен күрер өчен татарча сөйли торган гид яллыйлар.

Самар мәйданында экскурсиягә килүчеләргә авыз ачып Самар мәчетләре турында ник бер сүз әйтсеннәр. Димәк, туризм департаменты белән тыгызрак элемтәләр урнаштырырга кирәктер.

*Шамил БАҺАУТДИН.*

**Сорагыз - җавап бирәбез**

## «Фәсәд» сүзе ни аңлата?

«Бәкарә» сүрәсендә: "Аң булыгыз! Шул монафикълар кешеләр арасын бозып, җир өстендә ***фәсәд кылучылар, ләкин шуны үзләре сизмиләр***".

*«Фәсәд»* сүзе ни аңлата?

* * *

*Фәсәд* - бозыклык

Парлы буласыгыз килсә, "Алеф"ка килегез!



Дөнья мәшәкатьләренә чумып үз тормышыгызны онытып җибәрмәгез.

Никадәр генә мул тормышта яшәсәгез дә, һөнәр иясе булсагыз да, торак урыныгыз яхшы булса да - бу әле чын бәхет түгел.

Чын бәхет - ул эштән арып кайткач, сөйгәнеңнең елмаеп каршы алуы, кичләрен бергәләп сөйләшеп утыру, төннәрен хисләргә хозурлану.

Ходай Тәгалә барлык тереклекне парлы иткән.

Парлы яшәү - ул кешенең яшәешенә нур өсти, тормыш-көн күрүне җиңеләйтә, адәмнең гомерен озынайта.

Тулырак мәгълүматны түбәндәге телефон аша белә аласыз:

**8-919-800-01-49.**

"Алеф" фирмасының максаты бер - татар-башкортларны гаиләле итү, бәхетле итү.

**Самар өлкә Диния нәзарәтенең һәм Самар Җәмигъ мәчетенең сайты:**
**http://islamsamara.ru**
Мөхәррир - Илйас хәзрәт Гирфанов.

**Россия Үзәк Диния нәзарәтенең сайты:**
**http://cdum.ru**

**Самар татарларының рәсми сайты:**
**http://tatarlarsamara.org**
Мөхәррир - Наилә Сабирҗанова.

**Тарихи мәчетнең сайты:**
**http://tarihi-mechet.ru**
Мөхәррир - Наил хәзрәт Биктаев.

**Самар татар радиосының сайты:**
**http://str63.ru**
Мөхәррир - Ирек Нуриев.

**«Дуслык» һәм «Ак бәхет» оешмаларының уртак сайты:**
**http://tatar-duslyk.ru**
Мөхәррир - Римма Нуретдинова.

**Татар эшбатырларының сайты**
**http://samtatdelo.ru**
Мөхәррир - Данияр Сәйфиев.

**«Яктылык» мәктәбенең сайты:**
**http://yaktylyk.ru**
Мөхәррир - Вагыйз Хәйруллов

## Безнең сүзлек

**Һу кошы** - Аллаһыга бирелгән кеше.

**Гарше шахи** - дини тәгълимат буенча, күкнең иң югары катлавында (тугызынчы катында) урнашкан Аллаһы тәхетен тотып торучы агач ботагы.

**При Самарской Соборной мечети работает специализированный магазин по продаже мяса и мясных продуктов стандарта "халяль"**

Магазин предлагает по умеренным ценам большой ассортимент мясных полуфабрикатов, колбас и колбасных изделий, приготовленных в цехах Алькино (Самарская область), Нижнекамска (Татарстан), Благовещенска (Башкортостан) и Саратова, а также хлебные изделия, различные консервы, минеральные воды и соки.



**Контактный телефон: 951-24-77.**

Объявление

Предлагается мясо говядина **(халял)** специализированной мясной породы. Возможна доставка.
Цена - 230 рублей.
**Телефон:**
**8 - 927 = 763 - 97 - 78**